ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАНАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова,
422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы,
422575

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1

23.10.2019 д. Канаш №37

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Канаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Уставының 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2019 елның 6 ноябренә Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Канаш авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. «2020 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган һәр авыл җирлеге кешесеннән 500 сум үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен алдагы эшләрне башкаруга җибәрү белән килешәсезме:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Канаш авылында чишмәләрне төзекләндерү;

« ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын Канаш авылы, Үзәк урамы, 32 йорт адресы буенча урнашкан торак йорт янында 10.00 сәгатьтә үткәрергә.

4. Канаш авыл җирлеге Башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге Башлыгы Н.Н.Вальков